РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава Асеевского сельского поселения Азнакаевского муниципального района
ул. Центральная, д.38Б, с. Асеево, Азнакаевский район, 423310

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Башлыгы
Үзәк ур., 38Б нче йорт, Әсәй авылы, Азнакай районы, 423310

Тел./факс(885592)43-2-37, 43-3-27; E-mail: Asv.Azn@tatar.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«13» ноябрь 2019 ел № 19

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына бюджеты турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын саклау максатларында, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Әсәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына бюджет проекты турында фикер алышуда катнашу өчен ачык тыңлаулар үткәрү юлы белән, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел № 131-ФЗ Федераль законның 28 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Әсәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының 22.04.2012 ел № 39 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегендә халык алдында тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә белән, карар чыгарам:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына бюджеты турында»гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.
2. Халык алдында тыңлаулар үткәрүнең инициаторы булып Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Башлыгы тора.
3. Билгеләргә:
- үткәрү вакыты-2019 елның 3 декабре 16.00 сәгатьтә;
- үткәрү урыны- Әсәй авыл мәдәният йорты;
- тикшерелгән мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр бирелә торган адрес: Әсәй авылы, Үзәк урам, 38Б йорт.
4. Гамәлдәге законнар, Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегенең норматив хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегенең норматив хокукый актлары һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2020, 2021 еллар план чорына бюджеты турында» карары проекты буенча ачык тыңлауларны әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Әлеге карарны һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына бюджеты турында»гы карар проектын Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында http//aznakayevo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлеш контролен үз артымнан калдырам.

Башлык: З.Ә. Идрисов.